КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 май г.Казань № 325

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» 2020 ел, 31 март, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» 2020 ел, 31 март, 237 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 март, 199 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1372 нче; 2022 ел, 1 март, 188 нче; 2022 ел, 11 июнь, 551 нче; 2023 ел, 30 март, 379 нчы; 2023 ел, 27 октябрь, 1363 нче; 2024 ел, 20 март, 167 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә 2023 – 2025 елларда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган комплекслы кадастр эшләрен үткәрү чаралары исемлеген;»;

әлеге карар белән расланган 2023 – 2025 елларда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә финанслашуы күздә тотылган комплекслы кадастр эшләрен үткәрү чаралары исемлеген яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 31 март, 237 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 май, 325 нче
карары редакциясендә)

## Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә 2023 – 2025 елларда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган комплекслы кадастр эшләрен үткәрү чаралары исемлеге

### I. Билгеле бер кадастр кварталлары территорияләрендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның $42^1$ статьясындагы 2 өлеше нигезендә башкарылырга тиешле чаралар (гамәлләр)

1) Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын төгәлләштерүне гамәлгә ашыру;

2) «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге Федераль законның $42^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә биналарның, корылмаларның, төзелеше төгәлләнмәгән объектларның урнашу урынын билгеләүне яки төгәлләштерүне гамәлгә ашыру;

3) биналар, шул исәптән күпфатирлы йортлар, корылмалар (линия объектлары булган корылмалардан тыш) урнашкан җир кишәрлекләре барлыкка килүне тәэмин итү;

4) мәйданнар, урамнар, юллар, яр буйлары, скверлар, бульварлар, су объектлары, пляжлар һәм башка объектлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре барлыкка килүне тәэмин итү;

5) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры белешмәләрендә җир кишәрлекләре чикләренең һәм биналар, корылмалар, төзелеше төгәлләнмәгән объектлар контурының урнашу урыны турында реестр хаталарын төзәтүне тәэмин итү.

II. Тиешле чараларны (гамәлләрне) башкаруга дәүләт контрактлары төзү өчен конкурс процедураларын оештыру һәм уздыру графигы (сроклары), шулай ук Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының чаралар үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вәкаләтле вазыйфаи затлары

| Т/с | Чараның исеме | Үтәү срогы | Вәкаләтле вазыйфаи затлар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | 2025 елда чикләрендә комплекслы кадастр эшләрен үткәрү планлаштырыла торган кадастр кварталлары исемлеген төзү һәм раслау | 2024 елның 22 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, муниципаль районнардагы һәм шәһәр округындагы җирле үзидарә органнарының (килешү буенча), Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (килешү буенча) вәкаләтле вазыйфаи затлары |
| 2. | «Пространство мәгълүматларының илкүләм системасы» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында комплекслы кадастр эшләрен башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында 2025 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирүгә Татарстан Республикасы заявкасын (алга таба – Заявка) әзерләү | 2024 елның 28 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 3. | Заявканы Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрүне тәэмин итү | 2024 елның 29 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 4. | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте белән Татарстан Республикасы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсә- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | Хөкүмәте арасында комплекслы кадастр эшләрен башкаруга субсидия бирү турында килешү төзүне тәэмин итү | федераль хезмәте тарафыннан билгеләнгән срокта | бәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 5. | Комплекслы кадастр эшләрен башкаручыларны сайлап алу буенча сатып алу чараларын башкару һәм «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә комплекслы кадастр эшләрен башкаруга дәүләт контрактларын төзү | 2025 елның 11 мартына кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 6. | Экономияләү хисабына барлыкка килгән акчаны файдалану максатларында комплекслы кадастр эшләрен башкаручыларны сайлап алу буенча кабат сатып алу чараларын үткәрү, дәүләт контрактларын төзү (кирәк булган очракта) | 2025 елның 5 маена кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 7. | Комплекслы кадастр эшләрен башлау турында гражданнарга һәм юридик затларга мәгълүмат бирүне тәэмин итү | Дәүләт контракты төзелгән көннән 10 эш көне эчендә | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, муниципаль районнардагы һәм шәһәр округындагы җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары |
| 8. | «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның $42^{10}$ статьясындагы 1, 2 өлешләре нигезендә җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссия- | Дәүләт контракты төзелгән көннән 20 эш көне эчендә | Шәһәр округының яки җирлегенең комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | ләрен (алга таба – килештерү комиссияләре) төзү | | |
| 9. | Территорияләрнең карта-планнары проектларын эшләү | 2025 елның 28 июленә кадәр | Комплекслы кадастр эшләрен башкаручы вәкаләтле вазыйфаи затлар |
| 10. | Килештерү комиссияләре утырышларын уздыру юлы белән җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү | 2025 елның 27 октябренә кадәр | Муниципаль районнардагы һәм шәһәр округындагы җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары; килештерү комиссияләре рәисләре |
| 11. | Территорияләрнең карта-планнарын раслау | 2025 елның 31 октябренә кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |
| 12. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләрне кертү өчен территорияләрнең карта-планнарын Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә кертү | 2025 елның 7 ноябренә кадәр | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты |

_______________